**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Об отмене ограничительных мероприятий (карантина), установленных на отдельных территориях Республики Татарстан в связи с их неблагополучием по заболеванию высокопатогенным гриппом птиц и угрозой его распространения

В связи с выполнением противоэпизоотических и профилактических мероприятий по ликвидации и предотвращению заболевания высокопатогенным гриппом птиц, в соответствии со статьей $3^1$ Закона Российской Федерации от 14 мая 1993 года № 4979-I «О ветеринарии», приказом Министерства сельского хозяйства Российской Федерации от 24 марта 2021 года № 158 «Об утверждении Ветеринарных правил осуществления профилактических, диагностических, ограничительных и иных мероприятий, установления и отмены карантина и иных ограничений, направленных на предотвращение распространения и ликвидацию очагов высокопатогенного гриппа птиц» **постановляю:**

1. Отменить ограничительные мероприятия (карантин), установленные в связи с неблагополучием по заболеванию высокопатогенным гриппом птиц и угрозой его распространения в пределах территории, занимаемой помещениями, используемыми крестьянским (фермерским) хозяйством «Фролов Эдуард Александрович» и расположенными в селе Калмаш Тукаевского района Республики Татарстан (далее – эпизоотический очаг), и в пределах территории радиусом 5 км от границ эпизоотического очага, включая село Калмаш, поселок Новый, село Верхний Байлар Тукаевского района Республики Татарстан (далее – угрожаемая зона).

2. Ограничить на территориях, указанных в пункте 1 настоящего Указа (за исключением птицефабрик, расположенных на территории угрожаемой зоны), в течение 90 календарных дней со дня отмены карантина вывоз птиц и инкубационного яйца.

3. Признать утратившим силу Указ Президента Республики Татарстан от 23 ноября 2021 года № УП-894 «Об установлении ограничительных мероприятий (карантина) на отдельных территориях Республики Татарстан в связи с их неблагополучием по заболеванию высокопатогенным гриппом птиц и угрозой его распространения».

4. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
30 декабря 2021 года
№ УП-1018

| УКАЗ<br>ПРЕЗИДЕНТА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ПРЕЗИДЕНТЫ<br>УКАЗЫ |
|---|---|---|

**Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә йогышлылыгы югары булган кош гриппы белән чирләү һәм аның таралу куркынычы янау белән бәйле рәвештә, аның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән чикләү чараларын (карантинны) бетерү турында**

Кошларның йогышлылыгы югары булган кош гриппы белән чирләвен бетерү һәм булдырмауга юнәлтелгән эпизоотиягә каршы һәм профилактик чаралар үтәлүгә бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^1$ статьясы, Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының «Йогышлылыгы югары булган кош гриппы таралуын һәм аның чыганакларын бетерүгә юнәлтелгән карантин һәм башка чикләүләр кертү һәм аларны бетерү буенча профилактика, диагностика, чикләү һәм башка чараларны тормышка ашыру буенча ветеринария кагыйдәләрен раслау турында» 2021 елның 24 мартындагы 158 номерлы боерыгы нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Тукай районы Калмаш авылында урнашкан һәм «Фролов Эдуард Александрович» крестьян (фермер) хуҗалыгына кергән биналар территориясендә (алга таба – эпизоотия чыганагы) һәм Татарстан Республикасы Тукай районының Калмаш авылын, Яңа поселогын, Югары Байлар авылын кертеп, эпизоотия чыганагыннан 5 км радиустагы территория чикләрендә (алга таба – куркыныч янау зонасы) йогышлылыгы югары булган кош гриппы белән чирләү сәбәпле имин булмауга һәм чирнең таралу куркынычына бәйле рәвештә кертелгән чикләү чараларын (карантинны) бетерергә.

2. Әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгән территорияләрдә (куркыныч янау зонасы территориясендә урнашкан кошчылык фабрикаларыннан тыш) карантин бетерелгән көннән 90 календарь көн дәвамында яралгылы йомырка һәм барлык төрдәге тере кош-корт чыгаруны чикләргә.

3. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә йогышлылыгы югары булган кош гриппы һәм аның таралу куркынычы белән бәйле рәвештә, аларның имин булмавы сәбәпле чикләү чаралары (карантин) кертү турында»

2021 елның 23 ноябрендәге ПУ-894 номерлы Указын үз көчен югалткан дип таныrга.

4. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2021 ел, 30 декабрь
№ ПУ-1018